**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның 13 декабреннән | № 50-390

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль торак фондын арендага бирү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 27 маендагы 34-228 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү системасын камилләштерү, аренда шартларында аннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, «Конкуренцияне яклау турында» 2018 елның 4 июнендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2009 елның 27 маендагы 34-228 номерлы карары белән (2009 елның 13 августындагы 36-242 номерлы; 2010 елның 19 ноябрендәге 3-15 номерлы; 2011 елның 19 февралендәге 5-40 номерлы; 2011 елның 14 сентябрендәге 8-57 номерлы; 2012 елның 3 апрелендәге 12-94 номерлы; 2012 елның 4 июлендәге 13-115 номерлы; 2013 елның 10 апрелендәге 22-150 номерлы; 2021 елның 19 мартындагы 7-50 номерлы карарлар редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль торак фондын арендага бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 5 статьясының 5.1 пунктындагы 10 нчы абзацын «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы статусы бирелгән затка, «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә территория челтәре оешмасы статусы бирелгән затка» сүзләре белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы — В. М. Козлов